КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 5 сентябрь г.Казань № 778

Татарстан Республикасының дәүләт казна учреждениеләрен үзгәртеп оештыру турында

Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, шулай ук дәүләт мөлкәтеннән нәтиҗәле файдалану өлкәсендә дәүләт идарәсе системасын оптимизацияләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәте җитештерү-техник үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесен (алга таба – Үзәк) һәм «Татарстан Республикасының Янгыннан саклау» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесен (алга таба – Учреждение), Учреждение эшчәнлегенең төп юнәлешләрен һәм максатларын саклап, Үзәкне Учреждениегә кушу юлы белән үзгәртеп оештыру турындагы тәкдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Учреждениенең гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы гамәлгә ашыра дип;

Учреждениенең штат санын саклап, тапшыру акты нигезендә Учреждение кушыла торган Үзәкнең хокук дәвамчысы була дип.

3. Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

дәүләт казна учреждениеләрен үзгәртеп оештыруга бәйле чараларны законнар нигезендә үткәрергә;

дәүләт казна учреждениеләрен үзгәртеп оештыру чараларын финанслауны 2019 елга Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгын һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләрен тотуга күздә тотылган акча исәбеннән тәэмин итәргә;

30 көн эчендә Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына оператив идарәгә тапшыру өчен Үзәккә элегрәк беркетелгән күчмә һәм күчемсез мөлкәт исемлеген Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы адресына җибәрергә.

4. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 60 көн эчендә Үзәккә элек беркетелгән күчемле һәм күчемсез мөлкәт объектларын, җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына билгеләнгән тәртиптә беркетергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин